Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Күн авыл җирлеге Советы

Күн авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

1 июль, 2026 ел № 8

Күн авылы

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында 2017 елның 21 августындагы 63 номерлы нигезләмә (2017 елның 13 декабрендәге 78 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 90 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 133 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 58 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 65 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Күн авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре шәхси торак төзелеш зонасында «дини йолаларны гамәлгә ашыру» (Ж1) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы адресы буенча урнашкан 1000 кв.м. мәйданлы, кадастр номеры 16:33:040412:1295 булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең гавами тыңлауларны оештыручыга - башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 17 июленнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

СОВЕТ КОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Питрәч муниципаль районының
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов